**ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районынын «Салагыш авыл җирлегенең» муниципаль берәмлеге Татар Чилчә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**06.12.2021** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021елның «06» декабре 8 сәгать 30 минутта узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

"2022 елда Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Татар Чилчәсе торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, ялгыз карт гражданнардан (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм irektән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә узара салым акчалары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

-Татар Чилчәсе авылының Урман урамы юлын ремонтлау өчен вак таш сатып алу;

- Татар Чилчәсе авылы урамнарын кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу);

- Татар Чилчә авылында лампаларны, дроссельләрне, фонарьларны һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу, ремонтлау һәм алыштыру;

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гранданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 26 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны-20 кеше, бу 77% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенынңда 20 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Татар Чилчәсе торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Татар Чилчә торак пункты территориясендэ, I төркем инвалидлардан, ялгыз карт гражданнардан (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм иректән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә узара салым чаралары җыюны кертүгә.

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

-Татар Чилчәсе авылының Лесная урамы юлын ремонтлау өчен вак таш сатып алу;

- Татар Чилчәсе авылы урамнарын кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу);

- Татар Чилчә авылында лампаларны, дроссельләрне, фонарьларны һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу, ремонтлау һәм алыштыру;

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.agryz.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче М.М. Мөхәммәдиев